**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 июль № 522

г. Казань

Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына әлеге карарга кул куелганнан соң 30 көн эчендә үзенең норматив хокукый актларын бу карарга туры китерергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\522.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 июль, 522 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары (алга таба – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары) сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – министрлык) тарафыннан юридик затларга, аларның җитәкчеләренә һәм башка вазыйфаи затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм аларның вәкаләтле вәкилләренә (алга таба – күзәтчелек объектлары) тикшерүләр (алга таба – тикшерүләр) оештыру һәм үткәрү юлы белән күзәтчелек объектларының автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән автомобиль юлларына куркынычсызлык таләпләрен тәэмин итү эшләрен оештыру һәм үткәрү өлкәсендәге федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) бозуларын кисәтү, ачыклау һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасының төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген (алга таба – төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге) гамәлгә ашыру процедурасын билгели.

2. Күзәтчелек объектлары – автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән автомобиль юлларына куркынычсызлык таләпләрен тәэмин итү эшләрен оештыру һәм үткәрү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр.

3. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар булып түбәндәгеләр тора:

а) Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры;

б) Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары;

в) Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының автомобиль юллары бүлеге мөдире һәм бүлекнең «белгечләр» категориясендәге дәүләт граждан хезмәткәрләре.

4. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

а) мотивлаштырылган язма соратулар нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә

органнарыннан, шулай ук күзәтчелек объектларыннан тикшерүне үткәрү өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар соратып алырга;

б) эш таныклыгын һәм Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының (Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары) тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен күрсәтеп, киртәләрсез күзәтчелек объектлары тарафыннан файдаланыла торган территорияләргә, биналарга, корылмаларга барып йөрергә;

в) күзәтчелек объектларына мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә;

г) вәкаләтле органнарга мәҗбүри таләпләрне бозуга бәйле материаллар җибәрергә.

5. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга, шул исәптән күзәтчелек объектларына тикшерүләр оештыру һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон (алга таба – ФЗ-294 нче Федераль закон) нигезләмәләре кулланыла.

6. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге кысаларында планлаштырылган һәм планнан тыш документларга яки күчмә тикшерүләр оештыру һәм үткәрү тәртибе ФЗ-294 нче Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тикшерүләр үткәргәндә ФЗ-294 нче Федераль законның 15 һәм 18 статьяларында билгеләнгән чикләүләрне сакларга һәм вазыйфаларны башкарырга, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә аларга бирелгән вәкаләтләрне тиешенчә үтәмәгән өчен җавап тотарга тиеш.

8. Тикшерү предметы булып күзәтчелек объектлары тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру процессында төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту, шул исәптән автомобиль юлларына куркынычсызлык таләпләрен тәэмин итү эшләрен оештыру һәм үткәрүгә мәҗбүри таләпләрне үтәүләре тора.

9. Төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда административ процедуралар вакытлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының дәүләт вазыйфаларын башкару буенча административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче карары нигезендә эшләнә һәм раслана торган административ регламентта билгеләнә.

10. Әлеге Тәртиптә күрсәтелгән вазыйфаи затларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә мөмкин.

_______________________________